**Республика Татарстан**
**Совет Альметьевского**
**сельского поселения**
**Сармановского**
**муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль**
**районы Әлмәт авыл**
**җирлеге советы**

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2018 ел,19 ноябрь

№ 25

**«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Әлмәт авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Әлмәт авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затының хезмәткә түләү нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 27 апрелендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 28 мартындагы 940 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карары нигезендә, Сарман муниципаль районы Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Әлмәт авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затының хезмәткә түләү нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 27 апрелендәге 25номерлы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советы карарына үзгәреш кертергә.

1. 1 нче кушымтаның 3 пунктындагы 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлмәт авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затының хезмәткә түләү чыгымнары елына айлык акчалата бүләкләүне түләү өлешендә 6.72 айлык акчалата бүләкләүне тәшкил итә.

2. 2018 елның 01 октябрендәге штат расписаниесен расларга һәм яңадан исәпләп чыгарырга.

3. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Әлмәт авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының сайланулы вазыйфаи Әлмәт авыл җирлегенең хезмәт өчен түләү нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 20 июнендәге 67 номерлы карарын юкка чыгарырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» http://pravo.tatarstan.ru һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында http:/ sarmanovo.tatarstan.ru адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге
Советы Рәисе Д.Ә. Газизов